**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422617, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел: 89872742637

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422617, РТ, Лаеш район, Мысовский
поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89872742637

---

**2021 елның 24 ноябре** **48 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегенең Мысовский торак пунктында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегенең Курманаково торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2022 елда Лаеш муниципаль районының Куюково авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2022 елда үзара салым акчаларын 1500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- поселок эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырларны ремонтлау, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Мысовский поселогында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Мысовский поселогында юлларны кардан чистарту, чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- җәй көне Мысовский поселогында (ГСМ, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) территорияне чаптыру;
- Мысовский поселогында, Үзәк урамда суүткәргеч челтәрне (материал сатып алу, суүткәргеч салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) алыштыру.

3. Әлеге карарны Көек авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______ Р.Ю. Зотин**

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Көек авыл җирлеге**
**Советы рәисе ____________ Р.Ю. Зотин**